**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НИЖНЕКУЮКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

Ул. Татарстан, д.71а, село Нижний Куюк, 422741
Тел.: (8-84369) 33-2-47; факс: 33-2-47

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ТҮБӘН КӨЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Татарстан урамы., 71а йорты, Түбән Көек авылы, 422741
Тел.: (8-84369) 33-2-47; факс: 33-2-47

# КАРАР

“17” гыйнвар 2022 ел № 1

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2021 елның 6 августында 18 нче номерлы карары белән кабул ителгән “Түбән Көек авыл җирлеге территориясендә адреслар бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентына” үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру» турындагы Федераль закон нигезендә, Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл башкарма комитеты карар бирә:

1. Түбән Көек авыл башкарма комитеты җитәкчесенең 2021 елның 06 августындагы 18 нче номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Түбән Көек авыл җирлеге территориясендә адреслар бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 1.5 пунктының 2 һәм 10 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Регламентта кулланыла торган төшенчәләр дәүләт адреслы реестрын алып бару һәм федераль мәгълүмати адреслы системаны эксплуатацияләүгә бәйле Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, 2013 нче елнын 28 декабрендәге 443-ФЗ номерлы «Федераль мәгълүмати адреслы система һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында"гы Федераль закон, 2014 чне елнын 19 ноябрендэге 1221 номерлы "Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару Кагыйдәләрен раслау турында"гы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә төгәл итеп кулланыла».

1.2. 1.5 пунктының 11-17 абзацларын 3-9 абзацлар дип санарга;

1.3. 2.6.1 пунктының 4-7 пунктчаларында «Башкарма комитет» сүзен «төзелгән килешү нигезендә муниципаль районның җирле үзидарә органы яки Башкарма комитет " сүзләренә алмаштырырга»;

1.4. 2.6.1 пунктының 8 пунктчасында «Башкарма комитет» сүзен «төзелгән килешү нигезендә Башкарма комитет яки муниципаль район җирле үзидарә органы " сүзләренә алмаштырырга»;

1.5. 2.6.4 пунктында «Башкарма комитетның структур бүлекчәсе» сүзләрен «муниципаль районның җирле үзидарә органнары, Башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга».

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында

(http://pravo.tatarstan.ru) һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе Галиәхмәтов Д.М.